МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.12.2021 г.Казань № 971

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 15 февралендә 8887 номеры белән теркәлде

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:

1. Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын раслау турында.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 16 маендагы 261 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча

дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 11 июлендәге 532 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 8 маендагы 341 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 14 ноябрендәге 1030 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 апрелендәге 279 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 июнендәге 451 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 28 сентябрендәге 673 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 июнендәге 437 номерлы.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның
«29» декабрендәге 971 номерлы
боерыгы белән расланды

# Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмаларына туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән гражданнар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмалары (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Халыкның мәшгульлек үзәгенед урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы, рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) һәм күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары урнашкан урын, аларның эш графигы турындагы мәгълүматлар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү регистры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) урнаштырылган.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган органнарның (оешмаларның) исемнәре турындагы белешмәләр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында (http://www.mtsz.tatarstan.ru) урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотучы вазыйфаи затлар турында мәгълүмат әлеге Регламентның (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, халыкның мәшгульлек үзәгенең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телл-

рендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәгенең эш вакыты һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаларны кабул итү графигы турындагы мәгълүматны үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның, халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында. Министрлыкның һәм халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәгенең эш вакыты һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаларны кабул итү графигы турындагы мәгълүматны үз эченә ала;

Татарстан Республикасы порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

«Работа в России» мәшгульлек һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформасында (алга таба – «Работа в России» порталы).

Бердәм порталда, «Работа в России» порталында, Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм чорлары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү чорлары һәм тәртибе турында мәгълүмат алу мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;

3) күпфункцияле үзәккә һәм (яки) күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.

4) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

5) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә (электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның, халыкның мәшгульлек үзәкләренең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт оешмасының яки муниципаль оешманың оешу-

хокук рәвешендә төзелгән (шул исәптән автономияле оешма булып тора торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон рәвештә дә, «бер тәрәзә» калыбы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

БИАС – электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 3 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү.

### 2.2. Башкарма хакимият органы (оешма) атамасы

Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмалары күрсәтә.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләрне бирү тора:

1) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының

«Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның рәвешләрен раслау турында» 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыгы (алга таба – 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык) белән расланган үрнәк буенча эшкә юллама;

2) туры килә торган эш вариантлары исемлеге;

3) халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимнәр;

4) өч яше тулганчы бала карау буенча ял чорында хатын-кызларга эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку узарга тәкъдимнәр.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

шәхсән;

«Работа в России» порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә.

### 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты гариза кабул ителгән көннән ике эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.4.2. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә үзе турында, квалификация дәрәҗәсе һәм эш стажы турында мәгълүмат (алга таба – резюме) белән бергә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган рәвешләр буенча «Работа в России» порталын, Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, электрон документ рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыра (әлеге Регламентка 4 нче кушымта).

Гаризаны Бердәм порталны яисә Татарстан Республикасы порталын кулланып юллаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче «Работа в России» порталын кулланып, гариза юлланган көннән

алып 3 календарь көннән дә соңга калмыйча резюме җибәрә. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә резюмены билгеләнгән вакытка җибәрү кирәклеге турында хәбәр җибәрә.

2.5.2. Электрон рәвештәге гариза һәм резюме халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган, тикшерү сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

2.5.3. Туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән мөрәҗәгать итүче (алга таба – теркәлгән мөрәҗәгать итүче) 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документларны шәхсән тапшыра, шул исәптән:

чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

белем һәм (яки) квалификация турында хәрби һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмалары тарафыннан бирелә торган, шулай ук 1992-1995 елларда Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырган оешмалар тарафыннан бирелгән документлар;

белем алу һәм (яки) квалификация турында һәм белем алуга бәйле, чит ил дәүләте территориясендә бирелгән документлар һәм аларның нотариаль яктан таныкланган рус теленә тәрҗемәсе.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача эш хакын исәпләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы карары белән расланган Соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача эш хакын исәпләү кагыйдәләренең 3 пунктында каралган очракларда, теркәлгән мөрәҗәгать итүче соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача хезмәт хакы турында белешмә тапшыра.

2.5.4. Теркәлгән мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне раслый торган документларны шәхсән тапшыра ала:

а) аның «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – Халыкның мәшгульлеге турындагы закон) 5 статьясында каралган эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар категориясенә кертелүен, шулай ук түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала торган:

иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче оешмалардан чыгарылуы турында;

качаклар яки мәҗбүри күченүчеләр категориясенә кертелүе турында;

хәрби хезмәттән куылуы турында яки хәрби хезмәттән куылган гражданин

белән туган булуы турында;

балигълык яшенә җитмәгән балаларны, гарип балаларны тәрбияләүче ялгыз һәм күп балалы ата-аналар категориясенә кертелүе турында;

Чернобыль һәм башка радиация һәлакәтләре һәм катастрофалар аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар категориясенә кертелүе турында;

б) теркәлгән мөрәҗәгать итүченең гыйльми дәрәҗәсе һәм исемнәре турында белешмәләр.

2.5.5. Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр һәм аннан соң килгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне күрсәтә:

Россия Федерациясе паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);

шәхесне таныклый торган документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен).

2.5.6. Чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Тәрҗемәнең дөреслеге һәм тәрҗемәче имзасының чын булуы нотариус тарафыннан таныкланган булырга тиеш.

2.5.7. Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

«Работа в России» порталындагы шәхси кабинет аша;

Бердәм портал аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша;

халыкның мәшгульлек үзәгенә «Работа в России» порталына керүне тәэмин итеп, шәхсән килгән очракта.

2.5.8. Мөрәҗәгать итүче үз ихтыяры белән шәхсән килеп халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә күпфункцияле үзәккә электрон рәвештә гариза һәм резюме тапшыруда ярдәм сорап яки халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме буенча туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә «Работа в России» порталына, Бердәм порталга һәм Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм атутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге яки күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәгеләр алына:

паспортның хакыйкыйлыгы турында мәгълүмат – Россия Эчке эшләр министрлыгы (ведомство мәгълүмат системасы);

яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр – Россия ЭЭМ (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт эшчәнлеге, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт стажы турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

мәҗбүри пенсия иминияте өчен иминият кертемнәре түләнгән соңгы эш (хезмәт) урыны буенча түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

гариплек турында белешмәләр (гарип затны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия фонды («Гарип затларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

белеме, квалификациясе турында белешмәләр – Рособрнадзор («Белем турында һәм (яки) квалификация, белем алу турында документлар турында мәгълүматларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

лаеклы ял алды яшендәге гражданнарга кертелү турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасы);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар – Россия ФСХ (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр – Россия ФСХ (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры);

юридик затларны гамәлгә куючылар (катнашучылар) булган гражданнар турында белешмәләр – Россия ФСХ (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусы турында мәгълүмат – Россия ФСХ («Һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусын тикшерү» гавами сервисы;

адвокат статусы турында белешмәләр – Россия Юстиция министрлыгы (Россия Федерациясе субъектларының адвокатлар реестры);

нотариус вәкаләтләре һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар турында белешмәләр – Россия Юстиция министрлыгы (нотариуслар һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар реестры);

бала туу турында белешмәләр (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия ФСХ (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

гражданинның үлеме турында белешмәләр – Россия ФСХ (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

пенсия алу факты турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

гражданнарны ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясенә кертү турында мәгълүмат (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия фонды (Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасы).

2.6.2. Ведомстволар арасында җибәрелә торган мөрәҗәгать ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрнераслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.4. Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.5. Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

2.6.6. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткән өчен Мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 72 пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итүдән баш тарту өчен нигез түбәндәгеләр булып тора:

халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүченең резюмены гариза җибәргәннән соң өч календарь көн узганчы халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрмәве;

резюменың мәгълүматка карата таләпләргә туры килмәве;

мөрәҗәгать итүченең, аның резюмесы «Работа в России» порталында урнаштырылган мәгълүматка карата таләпләргә туры килүе шарты белән, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның һәм резюменың аның яшәү урынына карамаган мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең билгеләнгән чорда халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәве.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Туры килә торган эш эзләү, эшсез гражданнарны теркәү максатларында гражданнарны теркәү, туры килә торган эш сайлауга карата таләпләр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 8 апрелендәге 460 номерлы карарына үзгәреш кертү, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары) нигезендә җибәрелгән электрон документ рәвешендәге гариза һәм резюменың тапшырылмавы;

ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып,

Россия ЭЭМ ведомствоара гариза җибәрү нәтиҗәсендә паспортның хакыйкыйлыгы турында белешмәләр булмавы.

2.8.3. Мөрәҗәгать итүче алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләрнең булмавы нигез булып тора:

Россия Федерациясе гражданины паспортының яки аны алмаштыра торган документның (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документларның (чит ил гражданнары өчен);

гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документларның (гражданлыгы булмаган затлар өчен).

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза «Работа в России» порталын кулланып, чират тәртибендә бирелә.

2.12.2. Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.12.3. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, «Работа в России» порталын дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

## 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә дә

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате

кирәкле барлык документлары белән гариза һәм резюме алынган көнне теркәлә.

Гариза һәм резюме мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзенең яшәү урыны буенча карамаган халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән очракта, резюме мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көнне мәгълүматка карата таләпләргә туры килү шарты белән, гариза халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителә (теркәлә). Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү кирәклеге турында белдерү резюмены бәяләү процедурасы тәмамланганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.13.2. Гариза һәм резюме халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән зат тарафыннан ял көне яки эшләми торган бәйрәм көнендә җибәрелгән очракта, гариза җибәрү көне дип аның артыннан киләсе эш көне санала.

Гаризаны кабул итү турында белдерү халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затка аны кабул иткән көнне җибәрелә.

2.13.3. Күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәктән, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыныннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән гариза тапшырылган көнне язу бирелә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән гарип затларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның гарип затлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән гарип затларларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.3.4 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Гарип затларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче

технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган гарип затларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) гарип затка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, гарип затка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) гарип затларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавыш белән һәм күрсәтеп белдерелә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм язулы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Гариплеге булган затларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) гарип затларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча гарип затларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) гарип затларга башкалар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң үзгәртеп кору, яңарту уздырылган, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның гарип затлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар

белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалана алу (шул исәптән тулы күләмендә) яки файдалана алмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм чорлары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү мөмкинлеге (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән, «Работа в России» порталында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән);

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның үрнәкләрен алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, «Работа в России» порталы, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге;

гарип затларга башкалар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара

хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ рәвешендә – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 20 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт хезмәте (консультацияләү һәм гариза һәм резюмены кабул итүдән тыш) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм резюме теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе халыкның мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары белән төзелә торган үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына, ә күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарының мөрәҗәгать итүчеләр белән – күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарының эш регламенты белән.

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль тәртип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль тәртиптә күрсәтелгән очракта) һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүдән тыш, теркәлгән гражданнарга туры килә торган эш вариантлары исемлеген җибәрүдән тыш, электрон рәвештә күрсәтелми.

2.16.2. Гариза, туры килә торган эш вариантлары исемлеге Татарстан Республикасы Порталы, Бердәм портал, «Работа в России» порталы аша җибәрелә ала.

2.16.3. Гаризаны төзү, гаризаны һәм резюмены өстәмә рәвештә нинди дә булса башка рәвештә тапшыру зарурлыгыннан тыш, «Работа в России» порталында яки Бердәм порталда гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Гаризаны Бердәм порталны яисә Татарстан Республикасы порталын кулланып юллаган очракта, мөрәҗәгать итүче «Работа в России» порталын кулланып, гариза юлланган көннән алып 3 календарь көннән дә соңга калмыйча резюме җибәрә.

2.16.4. Яңадан теркәлү даталары арасында, «Работа в России» порталына буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүмат кергән көннән алып

ике эш көненнән дә соңга калмыйча, халыкның мәшгульлек үзәкләре мөрәҗәгать итүчеләргә, «Работа в России» порталыннан файдаланып, туры килә торган эш (вакансия) вариантлары исемлеген җибәрәләр.

2.16.5. Мөрәҗәгать итүчеләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итү өчен язу) Татарстан Республикасы порталы, халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгендә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы порталы яки халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Мөрәҗәгать итүчегз дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гаризалар төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән затларга дәүләт хезмәте күрсәтү;

5) мөрәҗәгать итүчеләр алга таба тагын мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү;

6) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга тели икән, халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, язмача консультация бирә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчегә теркәлү исәбенә кую өчен кирәкле гамәлләрнең барышы һәм эзлеклелеге турында хәбәр итә, шул исәптән тапшырыла торган документларның эчтәлеге, рәвеше һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча да.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчедә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм атутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, мөрәҗәгать итүче риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

Үтәү вакыты: процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе

турында мәгълүмат бирү.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза һәм документлар тапшыру.

Мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәгенә «Работа в России» порталын, Бердәм порталны яки Татарстан Республикасы порталын кулланып электрон документ – гариза рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы порталы аша электрон рәвештә бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы Порталында авторизацияләнә;

Татарстан Республикасы порталында электрон гариза рәвешен ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү белешмәсен раслый (электрон гариза рәвешендә ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Мөрәҗәгать итүче «Работа в России» порталы аша электрон рәвештә гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталында расланган исәпкә алу язуын кулланып, «Работа в России» порталына керә;

«Работа в России» порталында электрон гариза рәвешен ача;

«Работа в России» порталында гариза рәвешен тутыра;

үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын раслый;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса).

Төзелгән һәм имзаланган гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә «Работа в России» порталы, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура 30 минут башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза һәм резюме тапшыру.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм резюмены күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша бирә ала.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Күпфункцияле үзәк белгече гаризаны һәм резюмены электрон рәвештә тапшыруга ярдәм итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе (гаризаларны кабул итү өлешендә) – хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Үтәү вакыты: процедура гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза һәм резюме тапшыру.

3.3.3. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә, халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән бару юлы белән, гариза һәм резюмены электрон рәвештә бирүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә «Работа в России» порталына, Бердәм порталга һәм Татарстан Республикасы Порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза һәм резюме тапшыру.

3.3.4. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.4.1 Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате халыкның мәшгульлек үзәгендә кирәкле барлык документлары белән гариза һәм резюме алынган көнне теркәлә. Гариза ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә алынган очракта – халыкның мәшгульлек үзәгенең ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән соңгы беренче эш көнендә.

3.3.4.2. Гариза һәм резюме мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына карамаган мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән очракта, резюме мәгълүматка карата таләпләргә туры килү шарты белән, гариза халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көнне кабул ителә. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү кирәклеге турында белдерү резюмены бәяләү процедурасы тәмамланганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

3.3.4.3. Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында билгеләнгән нигез булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, белдерү җибәрә.

Процедураны үтәү вакыты:

гариза җибәргәннән соң дүртенче көнгә (халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән гражданин резюмены тиешле чорда халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрмәгән очракта)

резюмега бәяләү уздырылган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча (резюме мәгълүматка карата таләпләргә туры килмәгән очракта);

халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән бару өчен билгеләнгән чор бетеп, аннан соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча (резюме «Работа в России» порталында урнаштырылган мәгълүматка карата таләпләргә туры килүе шарты белән, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза һәм резюме аның яшәү урынына

карамаган мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән чорда халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгәндә).

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаны кабул итүдән баш тарту турында белдерү җибәрү.

3.3.4.4 Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында билгеләнгән нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

мөрәҗәгать итүченең резюмесын «Работа в России» порталында урнаштырыла торган мәгълүматка карата Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча федераль хезмәт тарафыннан расланган таләпләргә туры килү-килмәве буенча бәяли. Мөрәҗәгать итүченең резюмесы мәгълүматка булган таләпләргә туры килгән очракта, гариза яшәү урынына карамаган халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән очраклардан тыш, халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителгән дип санала.;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итә;

документларның (әгәр әлеге документлар мөрәҗәгать итүченең шәхси ихтыяры белән тапшырылган булса) һәм (яки) «Работа в России» порталын кулланып, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә алынган, теркәлгән гражданинның паспортының хакыйкыйлыгы турында белешмәләрнең, яшәгән урын буенча теркәлү турындагы, алган белем һәм (яки) квалификация турындагы, соңгы эш (хезмәт) урыны буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача хезмәт хакын санап чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы карары белән расланган тәртиптә исәпләп чыгарылган уртача хезмәт хакы турындагы, теркәлгән гражданинның хезмәт эшчәнлеге турындагы, хезмәт стажы турындагы белешмәләрнең булуын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

Мөрәҗәгать итүче соравы буенча гаризаны кабул итү көне һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турындагы белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелергә мөмкин яисә гаризаны теркәү турында мөрәҗәгать итүченең «Работа в России» порталында, Татарстан Республикасы порталында шәхси кабинетына белдерү җибәрелә ала. Гаризаны кабул итү турында белдерү халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затка аны кабул иткән көнне, Татарстан Республикасы порталында, Бердәм порталда, «Работа в России» порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә;

Процедураларны үтәү вакыты: гариза һәм резюме алынган көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаризаны теркәү.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче турында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнар, бюджетка карамаган дәүләт фондлары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына карый торган оешмалар карамагында булган түбәндәге белешмәләрне сората:

паспортның хакыйкыйлыгы турында белешмәләр;

яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр;

хезмәт эшчәнлеге, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында белешмәләр;

хезмәт стажы турында мәгълүмат;

мәҗбүри пенсия иминияте өчен иминият кертемнәре түләнгән соңгы эш (хезмәт) урыны буенча түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр турында белешмәләр;

гариплек турында белешмәләр (гариплеге булган затның хосусый тернәкләндерү яисә абилитацияләү программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта);

белем, квалификация турында мәгълүмат;

лаеклы ял алды яшендәге гражданнарга кертелү турында белешмәләр;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр;

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр;

юридик затларны гамәлгә куючылар (катнашучылар) булган гражданнар турында белешмәләр;

һөнәри керемгә салым түләүченең (үзмәшгуль) статусы турында белешмәләр;

адвокат статусы турында белешмәләр;

нотариус вәкаләтләре һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар турында белешмәләр;

бала туу турында белешмәләр (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта);

гражданинның үлеме турында белешмәләр;

пенсия алу факты турында белешмәләр;

гражданнарны ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясенә кертү турында мәгълүмат (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта).

Ведомстволар арасында җибәрелә торган мөрәҗәгать ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчене теркәү исәбенә куйганнан соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара мөрәҗәгатьләр җибәрү.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган белешмәләрне (документларны) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә соралган белешмәләрнең булмавы турында Халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән хәбәр.

3.4.3. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар һәм ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынган белешмәләр

нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында яисә әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә, ике нөсхәдә язма рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аларның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече исәпкә алу язуының теркәү санын беркетеп, мөрәҗәгат итүче тапшырган документлардагы белешмәләрне Физик затларның электрон регистрына кертү юлы белән, мөрәҗәгать итүчене теркәү исәбенә куя.

Процедураларны үтәү вакыты: халыкның мәшгульлек үзәгенә гариза кергән көнне яки, гариза мәшгульлек үзәгенең эш вакытыннан соң алынган очракта, икенче көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене теркәү исәбенә кую.

3.5. Беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән затларга дәүләт хезмәте күрсәтү

3.5.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгате административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән затларга дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) гаризада һәм резюмеда булган белешмәләр, шулай ук әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне юллау юлы белән алынган белешмәләр нигезендә Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар - физик затлар регистрына кертелгән мөрәҗәгать итүче турындагы белешмәләргә анализ һәм мәшгульлек турындагы законнар нигезендә аңа туры килә торган эшне билгеләү, түбәндәгеләр турында белешмәләр булуын яки булмавын исәпкә алып:

һөнәр (белгечлек), вазыйфа, эшчәнлек төре;

һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре;

соңгы өч айда соңгы эш урыны буенча исәпләнгән уртача хезмәт хакы;

эш шартларының тернәкләндерү һәм абилитацияләү буенча хосусый программада булган киңәш ителә торган характеры һәм шартлары;

2) мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр хакында мәгълүмат бирү:

теркәү исәбенә кую һәм туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гамәлләр барышы һәм эзлеклелеге, шул исәптән мондый гражданинга тиешле хәбәрләрне юллау чорлары турында;

Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның 4 статьясы нигезләмәләре турында;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары белән расланган туры килә торган эшне сайлап алуга карата таләпләр турында;

мөрәҗәгать итүченең туры килә торган эштән баш тартуы очрагында аның хокукый нәтиҗәләре турында;

хезмәт өлкәсендә хезмәткә хокук, мәҗбүри хезмәт һәм дискриминациягә

чикләү билгеле торган хезмәт законнары нигезләмәләре турында;

3) Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турындагы белешмәләрдән чыгып, мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш сайлап алу;

4) мөрәҗәгать итүче белән туры килә торган эш вариантларын килештерү;

5) эш бирүче белән мөрәҗәгать итүче кандидатурасын килештерү;

6) эшкә иң күбе ике юллама рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү;

7) мөрәҗәгать итүчегә эш бирүче тамгасы куелган эш юлламасын тапшыру кирәклеге турында хәбәр итү;

8) мөрәҗәгать итүче туры килә торган эш вариантына риза булмаган очракта, баш тартуны рәсмиләштерү;

9) туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта, мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләрне тәкъдим итү:

катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

эш бирүчеләр янына мөстәкыйль бару өчен, вакытлыча характердагы, алдан әзерлек таләп итә торган яки таләп итми торган, хезмәт законнары таләпләренә һәм башка, хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган норматив хокукый актларга җавап бирә торган, Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) булган, түләүле эш вариантлары;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның $7^{1-1}$ статьясында билгеләнгән башка дәүләт хезмәтләрен күрсәтү;

10) өч яше тулганчы баланы карау ялында булган, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан башларга омтылган эшсез гражданнарга һөнәри белем алырга яисә халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итү;

11) мөрәҗәгать итүчегә, ул риза булган очракта, түбәндәгеләрне рәсмиләштерү һәм бирү:

катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

эш вариантлары исемлеге;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим;

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча һөнәри белем алырга тәкъдим;

12) административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен Физик затлар регистрына кертү.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгәндә тапшырылган документлар нигезендә Физик затлар регистрына кертелгән мөрәҗәгать итүче турындагы белешмәләрне анализлау һәм аның өчен халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар нигезендә туры килә торган эшне билгеләү, түбәндәгеләр турында белешмәләр булуын яки булмавын исәпкә алып:

һөнәр (белгечлек), вазыйфа, эшчәнлек төре;

һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре;

соңгы өч айда соңгы эш урыны буенча исәпләнгән уртача хезмәт хакы;

эш шартларының тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең хосусый программасында булган киңәш ителә торган характеры һәм шартлары.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.5.3. Туры килә торган эш вариантларын сайлаганда мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә телдән хәбәр итә:

Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның «туры килә торган һәм туры килми торган эш» төшенчәләрен билгели торган 4 статьясы нигезләмәләре турында;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары белән расланган туры килә торган эшне сайлап алуга карата таләпләр турында;

мөрәҗәгать итүченең туры килә торган эштән баш тартуы очрагында аның хокукый нәтиҗәләре турында;

хезмәт өлкәсендә хезмәткә хокук, мәҗбүри хезмәт һәм дискриминациягә чикләү билгели торган хезмәт законнары нигезләмәләре турында;

туры килә торган эш вариантын сайлаган вакытта, аларны документаль раслаган очракта, гаризадагы мәгълүматларның исәпкә алынуы турында.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат бирү.

3.5.4. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турындагы белешмәләрдән чыгып, мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш сайлап алу

Яңадан теркәлү даталары арасында, «Работа в России» порталына буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүмат кергән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча, халыкның мәшгульлек үзәкләре эшсез гражданнарга, «Работа в России» порталыннан файдаланып, туры килә торган эш (вакансия) вариантлары исемлеген җибәрәләр.

Халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданинга кабаттан теркәү көннәре арасында туры килә торган эшне сайлап алу һәм килештерү, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән эш бирүчегә әңгәмәгә юллама бирү өчен эш бирүчегә шәхси килү датасын билгеләргә хокуклы. Халыкның мәшгульлек үзәкләре эшсез гражданинга эшсез гражданинны яңадан теркәү көнендә килү датасын күрсәтеп, хәбәр юллый.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, һөнәр (белгечлек), вазыйфа, эшчәнлек төре, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре, соңгы эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләме, хезмәт

шартлары һәм һәркем файдалана алырлык эш урыннары турында тәкъдимнәр, эш урынының транспорт белән файдалана алырлык булуы, мөрәҗәгать итүченең үз эшенә теләкләре, шулай ук кандидатның хезмәт функциясен үтәүгә карата эш бирүче таләпләреннән чыгып, туры килә торган эш вариантларын сайлап ала.

Эш бирүчедән алар өчен туры килә торган, телдән (телефоннан) яисә язма (электрон документ рәвешендә) рәвештә туры килә торган буш эш урыны һәм вакантлы вазыйфа булуы турында белешмәләр кергән очракта, алар турында белешмәләрне Физик затлар регистрында булган мөрәҗәгать итүчеләргә халыкның мәшгульлек үзәгенә өч көн эчендә эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү өчен килергә тәкъдим ителә.

Туры килә торган эшне сайлаганда рөхсәт ителми:

бер үк варианттагы эшне ике тапкыр тәкъдим итү, ә беренче тапкыр эш эзләүче, элек эшләмәгән һәм шул ук вакытта һөнәре (белгечлеге) булмаган гражданнар өчен бер үк төрле һөнәри әзерлек вариантын ике тапкыр тәкъдим итү;

эш урынына транспорт белән бару мөмкинлеген тәэмин итә торган җәмәгать транспорты челтәре үсешен исәпкә алмыйча, эш урыннарына юллау;

мөрәҗәгать итүчеләр ризалыгыннан башка яшәү урынын үзгәртүгә бәйле эш тәкъдим итү;

хезмәт шартлары хезмәт сагы кагыйдәләре һәм нормаларына туры килми торган эш тәкъдим итү;

эш хакы мөрәҗәгать итүченең соңгы эш урыны буенча соңгы өч айда исәпләнгән уртача хезмәт хакыннан түбәнрәк булган эш тәкъдим итү. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләп чыгарылган уртача айлык хезмәт хакы эшкә яраклы халыкның яшәү минимумы күләменнән артып киткән мөрәҗәгать итүчеләргә кагылмый.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) туры килә торган эш вариантлары булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне бастырып чыгара һәм аны мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне алу.

3.5.5. Мөрәҗәгать итүче белән туры килә торган эш вариантларын килештерү.

Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән яраклы эш вариантларын сайлап ала һәм эш бирүчегә әңгәмәгә җибәрүгә үз ризалыгын (ризасызлыгын) белдерә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән туры килә торган эш вариантын сайлап алу.

3.5.6. Эш бирүче белән мөрәҗәгать итүче кандидатурасын килештерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүче сайлап алган туры килә торган эш вариантлары нигезендә телефон аша эш бирүче белән әңгәмә

корырга юллама бирә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгать итүчегә телефон яки видеоэлемтә аша, Интернет челтәрен кулланып әңгәмә үткәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән мөрәҗәгать итүчене әңгәмәгә җибәрүне килештерү яки Интернет челтәреннән файдаланып, телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә үткәрү.

3.5.7. Әңгәмә узу өчен икедән артмаган юлламаны рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган үрнәктә икедән артмаган күләмдә эшкә юлламалар рәсмиләштерә һәм мөрәҗәгать итүчегә бирә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: икедән артмаган күләмдә эшкә юллама рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү.

3.5.8. Мөрәҗәгать итүчегә эш бирүче тамгасы куелган эш юлламасын тапшыру кирәклеге турында хәбәр итү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә, юллама бирелгән көннән алып өч көн эчендә эшкә урнашу мәсьәләсе буенча эш бирүче белән әңгәмәне үтү һәм әңгәмә нәтиҗәләре турында эш бирүче тамгасы белән эшкә бирелгән юлламаны халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшыру кирәклеге турында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә әңгәмә узу вакыты һәм эш бирүче тамгасы белән эшкә бирелгән юлламаны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итү.

3.5.9. Мөрәҗәгать итүченең ризалыгы булмаган очракта, туры килә торган эш вариантыннан баш тартуны рәсмиләштерү

Мөрәҗәгать итүче туры килә торган эш варианты белән язмача килешмәвен белдерә һәм шәхси имзасы белән баш тарту фактын раслый.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең тәкъдим ителгән эш вариантларыннан язмача баш тартуы.

3.5.10. Туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә:

катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар таләпләренә җавап бирә торган, эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен, вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, түләүле эш вариантлары;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның $7^{1-1}$ статьясында билгеләнгән башка дәүләт хезмәтләрен күрсәтү.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган

затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча ирекле эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча ирекле эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне бастырып чыгара һәм аны мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә.

Чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эш вариантларын мөрәҗәгать итүче белән килештерү һәм мөрәҗәгать итүче кандидатурасын эш бирүче белән килештерү әлеге Регламентның 3.5.5-3.5.6 пунктларында каралган гамәлләр эзлеклелеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эш вариантын сайлау яисә мөрәҗәгать итүченең Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның $7^{1-1}$ статьясында билгеләнгән халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләр күрсәтү турында тәкъдим белән ризалыгы.

3.5.11. Өч яше тулганчы баланы карау ялында булган, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан башларга омтылган эшсез гражданнарга һөнәри белем алырга яисә халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итү

Туры килә торган эш булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, туры килә торган эш эзләүдә ярдәм күрсәткәндә, өч яшькә җиткәнче бала карау ялындагы хатын-кызга, картлык буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңартырга омтылган эшсез гражданинга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алырга яки өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: өч яшькә җиткәнче бала карау ялында булган хатын-кызны, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңартырга омтылган эшсез гражданин өчен мәшгульлек органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу яисә өстәмә һөнәри белем бирү вариантын сайлап алу.

3.5.12. Мөрәҗәгать итүчегә, ул риза булган очракта, түбәндәгеләрне рәсмиләштерү һәм бирү:

катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлек.

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим;

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча һөнәри белем алырга тәкъдим.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) түләүле эшнең теләсә нинди вариантын сайлый, шул исәптән вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, эш вариантлары исемлеген

бастыра һәм эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен аны мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә.

Мөрәҗәгать итүчегә, ул риза булган очракта, чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү әлеге Регламентның 3.5.7 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән ризалашкан очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

вакантлы эш һәм уку өчен эш урыннары ярминкәсен үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Түләүле җәмәгать эшләрен үткәрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча федераль дәүләт стандарты раслау турында» 2013 елның 11 февралендәге 52н номерлы боерыгы белән расланган Түләүле җәмәгать эшләрен үткәрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча  федераль дәүләт стандартында каралган административ процедураларны гамәлгә ашыра.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү йортларын тәмамлаучылар һәм беренче тапкыр эш эзләүче затлар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 12 февралендәге 58н номерлы боерыгы белән расланган 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү йортларын тәмамлаучылар һәм беренче тапкыр эш эзләүче затлар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартында каралган административ гамәлләрне гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «14 яшьән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү йортларын тәмамлаучылар һәм беренче тапкыр эш эзләүче затлар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2014 елның 17 апрелендәге 262н номерлы боерыгы белән расланган 14 яшьән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү йортларын тәмамлаучылар һәм беренче тапкыр эш эзләүче затлар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) башкара.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган үрнәктә

рәсмиләштерелгән чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү;

эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим итү;

халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алырга тәкъдим итү.

3.5.13. Административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен Физик затлар регистрына кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Физик затлар регистрында түбәндәгеләрне терки:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен (мөрәҗәгать итүчегә эшкә юллама, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлек бирү, туры килә торган эш вариантыннан баш тарту);

халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте чараларында катнашу өчен юллау факты (мөрәҗәгать итүчегә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим биргәндә, халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча, шул исәптән, өч яше тулганчы бала карау ялында булган чорда хатын-кызларга халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан һөнәри уку узарга тәкъдим итү).

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш эзләүдә дәүләт хезмәте күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Физик затлар регистрында теркәү.

3.6. Мөрәҗәгать итүче алга таба тагын мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү

3.6.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында алга таба тагын мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче алга таба тагын шәхсән мөрәҗәгать иткән очракларда, туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүче алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда тапшырылырга тиешле, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерү;

2) эш юлламаларында эшкә алучы тамгасы белән яисә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмасына алдагы тапкыр килгәндә мөрәҗәгать итүчегә бирелгән эш вариантлары исемлеге нигезендә мөрәҗәгать итүченең эш бирүчеләргә бару нәтиҗәләре турындагы мәгълүматлары белән танышып чыгу;

3) мөрәҗәгать итүче тарафыннан өстәмә бирелгән документлардагы белешмәләрне һәм/яки башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен исәпкә алып, туры килә торган эш эзләү билгеләрен төгәлләштерү;

4) әлеге Регламентның 3.5.1 пунктындагы 3-12 пунктчаларында каралган административ гамәлләрне башкару.

3.6.2. Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

мөрәҗәгать итүче алга таба тагын мөрәҗәгать иткән очракларда күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документлар булуын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булып, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә, ике нөсхәдә язма рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аларның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

Баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече агымдагы архивтан мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматлары буенча элек тутырылган хисап документлары бланкларын ала.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдән язмача баш тартуы.

3.6.3. Эшкә юлламаларда эш бирүченең тамгасы белән яисә мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәгенә алдагы мәртәбә мөрәҗәгать иткән очракта мөрәҗәгать итүчегә бирелгән буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турындагы белешмәләрне үз эченә алган исемлек нигезендә эш бирүчеләр янына бару нәтиҗәләре турындагы мәгълүматлары белән танышып чыгу

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчеләр тарафыннан билгеләнгән эш юнәлешләрен кабул итә яки мөрәҗәгать итүчедән алдагы тапкыр мөрәҗәгать иткәндә сайланган исемлек буенча эш бирүче янына бару нәтиҗәләре турында ачыклый.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш юлламаларында эшкә алучы тамгасы белән яисә халыкның мәшгульлек үзәгенә алдагы тапкыр килгәндә мөрәҗәгать итүчегә бирелгән эш вариантлары исемлеге нигезендә мөрәҗәгать итүченең эш бирүчеләргә бару нәтиҗәләре турындагы мәгълүматлары белән танышып чыгу.

3.6.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан өстәмә бирелгән документлардагы белешмәләрне һәм/яки башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен исәпкә алып, туры килә торган эш эзләү билгеләрен төгәлләштерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече, мөрәҗәгать итүче тарафыннан өстәмә бирелгән документлардагы белешмәләрне һәм (яки) башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен исәпкә алып, мөрәҗәгать итүчедән аңа туры килә торган эш вариантларын эзләү билгеләрен ачыклый.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: туры килә торган эш эзләү билгеләрен ачыклау.

3.6.5. Әлеге Регламентның 3.5.1 пунктындагы 3-12 пунктчаларында каралган

административ гамәлләрне башкару

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Регламентның 3.5.4-3.5.13 пунктларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге нигезендә:

мөрәҗәгать итүче өчен туры килә торган эш вариантын сайлый;

чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча мөрәҗәгать итүче өчен эш вариантын сайлый;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның $7^{1-1}$ статьясында билгеләнгән башка дәүләт хезмәтләре күрсәтүне тәкъдим итә.

халыкның мәшгульлек хезмәте юлламасы буенча һөнәри әзерлек, яңадан әзерлек узарга яки квалификация күтәрергә, шул исәптән, өч яшькә җиткәнче бала карау буенча ял вакытында хатын-кызларга да, тәкъдим итә;

Физик затлар регистрында административ гамәлләрне үтәү нәтиҗәләрен терки.

Үтәү вакыты: процедуралар кабат мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган үрнәктә рәсмиләштерелгән эшкә юллама рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү;

2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык белән расланган үрнәктә чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү;

эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне мөрәҗәгать итүчегә бирү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим;

халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алырга тәкъдим итү.

3.7. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

Техник хата мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына ярашлы үрнәктә гариза бирелгән очракта төзәтелә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мәшгульлек үзәге тарафыннан компенсация билгеләү (компенсация билгеләүдән баш тарту) турында бирелгән карарда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында язмача гариза тапшыра.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра;

халыкның мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрә.

Процедураларны үтәү вакыты: күпфункцияле үзәкнең эш регламенты һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның (эш бирүчеләрнең) мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу өчен гражданнарның кандидатуралары исемлеген, эшкә юлламаны яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне, яисә өч яшенә җиткәнче бала карау ялында булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алуга юллау тәкъдимен яңадан рәсмиләштерә;

кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу өчен гражданнарның кандидатуралары исемлеген, эшкә юлламаны яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне, яисә өч яшенә җиткәнче бала карау ялында булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алуга юллау тәкъдимен яңадан рәсмиләштерү турында мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә;

Процедураларны үтәү вакыты: гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, яңадан рәсмиләштерелгән кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу өчен гражданнарның кандидатуралары исемлеге, эшкә юллама яисә эш вариантлары исемлеге, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим, яисә өч яшенә җиткәнче бала карау ялында булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алуга юллау тәкъдиме.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Халыкның мәшгульлек үзәге директоры яки аның вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольлек башкарыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольлек әлеге Административ регламентның, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын, аларга белешмәләр тапшыру тәртибен, чорларын һәм рәвешен дә кертеп, алып бару тәртибе турында» 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын, аларга белешмәләр тапшыру тәртибен, чорларын һәм рәвешен дә кертеп, алып бару тәртибенең,

мөрәҗәгать итүчеләрнең исәпкә алу документлары һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген билгели торган башка документларның кәгазьләрен тутыру, алып бару һәм саклауга карата таләпләр үтәлешен һәм сакланышын тикшерүләр юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыру вакыты халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан билгеләнә.

4.4. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүне контрольдә тоту кысаларында, эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өлешендә дәүләт гарантияләреннән тыш, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә күзәтчелек һәм контрольдә тоту вәкаләтләрен үтәү кысаларында Министрлык башкара.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итү Министрлык тарафыннан планлы (планнан тыш) күчмә (документар) тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Мөрәҗәгать итүчеләр (гражданнар), аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты (белгече) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә шикаять бирергә хокуклы.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль

законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

халыкның мәшгульлек үзәгенең, халыкның мәшгульлек үзәгендәге вазыйфаи затның (белгечнең) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны яки ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (оешманың), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (оешма), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты (белгече) яисә дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта, күпфункцияле үзәк, «Интернет» челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru) файдаланып, Татарстан Республикасы порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга

мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (оешма хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (белгеченең) яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (белгеченең) яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

Халыкның мәшгульлек үзәге, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән

чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (оешма), күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, халыкның мәшгульлек үзәге белгече булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 1 нче кушымта

Үрнәк

«Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна оешмасы

______________________________

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар
«__» ________ 20__ ел № ___

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20___ елның «___» ____________ № ____ боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентының 2.8 пункты нигезендә туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга ________________________________________.

Баш тарту сәбәбе:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече

______________________________

(ФИА, имза)

Карарны алды

________________________________________________________________

(Гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

«__» ________ 20__ ел.

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 2 нче кушымта

Үрнәк

«Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна оешмасы

________________________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) тулысынча күрсәтелә)

яши торган адрес ____________________________________________________

_____________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_____________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ исеме, аның сериясе, номеры, бирелгән датасы, документны биргән орган атамасы)

_____________________________________________________________________________,

техник хатаны төзәтүне сорыйм ______________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________,

20___ елның «___» _____________ бирелгән кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу өчен гражданнарның кандидатуралары исемлегендә, эшкә юлламада яисә эш вариантлары исемлегендә, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимдә, яисә өч яшенә җиткәнче бала карау ялында булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алуга юллау тәкъдимендә җибәрелгән (кирәклесе астына сызарга).

Үзгәртеп рәсмиләштерелгән кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу өчен гражданнарның кандидатуралары исемлеген, эшкә юлламаны яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне, яисә өч яшенә җиткәнче бала карау ялында булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алуга юллау тәкъдимен түбәндәгечә алырга риза:

_____________________________________________________________________________
(язмача, электрон почта аша, ТР Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша)

«__» ________ 20__ ел. ______________________________ ______________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 3 нче кушымта

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| Т/с | Мөрәҗәгать итү датасы | Гражданинның фамилиясе, исеме, ата исеме | Адрес | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать итү нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 4 нче кушымта

Үрнәк
Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыгы белән расланган

Туры килә торган эш эзләүдә гражданнарга ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

Мин эш эзлим һәм эшсез дип танылуга дәгъва белдермим
Мин эшсез дип танылуга дәгъва белдерәм
(кырларның берсен сайлагыз)

1. Фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)
2. Җенес
3. Туган көн
4. Гражданлыгык
5. Шәхесне раслаучы документ төре
6. Шәхесне раслаучы документның сериясе, номеры
7. Шәхесне раслаучы документны бирү датасы
8. Шәхесне раслаучы документ кем тарафыннан бирелгән
9. Шәхси тәңгәллек саннары
10. Хосусый шәхси счетның иминият саннары
11. Адрес:

а) яшәү урыны (эшсез дип танылуга дәгъва белдерүче гражданнар өчен мәҗбүри):
- Россия Федерациясе субъекты
- район, торак пункт, урам
- йорт, корпус, төзелмә, фатир

б) тору урыны (эшсез дип танылуга дәгъва белдерми торган гражданнар өчен яшәү урыны яки тору урыны адресы сайлап күрсәтелә):
- Россия Федерациясе субъекты
- район, торак пункт, урам
- йорт, корпус, төзелмә, фатир

12. Соңгы эш урыны турында мәгълүмат:

Эш тәҗрибәсе бар:

а) оешманың тулы исеме/шәхси эшкуарның/физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

б) һөнәр (вазыйфа), эш стажы

в) эштән китү датасы
г) эштән җибәрү турында боерык номеры
д) эштән азат итү нигезе
13. Элемтә ысулы:
а) телефон
б) электрон почта адресы
14. Хезмәт күрсәтү урыны:
а) Россия Федерациясе субъекты
б) халыкның мәшгульлек үзәге
15. Эш эзләү буенча Россия Федерациясе субъекты (эш эзләү башкарылачак өч субъектны сайларга мөмкин)
16. Пособие алу ысулы (кырларныд берсен сайлагыз):
а) исәп-хисап счеты:
- «Мир» илкүләм түләү системасы картасы номеры
- алучы банкның исеме
- алучы банкның тәңгәллек коды
- алучының счеты
- алучы банкның шәхси тәңгәллек саннары
- алучы банкның корреспондент счеты;
б) почта аша күчерү субъекты (адрес)
17. Әгәр сез түбәндә санап үтелгән гражданнарның берәр категориясенә карыйсыз икән, бу хакта күрсәтегез:

| Эшсез дип танылуга дәгъва итүче гражданнар өчен | Эшсез дип танылуга дәгъва итми торган гражданнар өчен |
|---|---|
| Пенсия алды яшендәге гражданнарга карыйм (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында)<br>Гарип<br>Ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясенә карыйм<br>Россия Федерациясендә теркәлгән, 18 яшькә кадәрге балам (балаларым) бар<br>туу факты Россия Федерациясендә теркәлгән, 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) опекуны, уллыкка алучысы булып торам<br>туу факты чит илнең вәкаләтле органы тарафыннан теркәлгән, 18 | Эшлим, тик эшне үзгәртергә/өстәмә эш табарга телим<br>Көндезге уку рәвешендә белем алам<br>Пенсия алды яшендәге гражданнарга карыйм (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында)<br>Гарип<br>Ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясенә карыйм<br>Россия Федерациясендә теркәлгән, 18 яшькә кадәрге балам (балаларым) бар<br>туу факты Россия Федерациясендә теркәлгән, 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) опекуны, уллыкка алучысы булып торам |

| | |
|---|---|
| яшькә кадәрге балам (балаларым) бар<br>Ирекләреннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче оешмаларыннан азат ителгән зат булам<br>Качак/мәҗбүри күченүче булып торам<br>Мин хәрби хезмәттән азат ителгән гражданин/аның гаилә әгъзасы;<br>Мин балигъ булмаган балалар, гарип балалар тәрбияләүче ялгыз/күп балалы әти-әни булып торам<br>Чернобыль һәм башка радиация һәлакәтләре һәм катастрофалар аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданин булам<br>Мин 16-18 яшьтәге балигъ булмаган бала булып торам<br>18 яшьтән 25 яшькә кадәр, урта һөнәри белем яисә югары белем алган һәм белем һәм квалификация турында документ бирелгән көннән алып ел дәвамында эш эзләүче гражданин булып торам | туу факты чит илнең вәкаләтле органы тарафыннан теркәлгән, 18 яшькә кадәрге балам (балаларым) бар<br>Пенсионер булып торам<br>Хәрби пенсионер булып торам<br>3 яшькә кадәр бала карау ялында утыручы хатын-кыз булып торам<br>Мин 14-18 яшьтәге балигъ булмаган бала булып торам<br>Ирекләреннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче оешмаларыннан азат ителгән зат булам<br>Качак/мәҗбүри күченүче булып торам<br>Мин хәрби хезмәттән азат ителгән гражданин/аның гаилә әгъзасы;<br>Мин балигъ булмаган балалар, гарип балалар тәрбияләүче ялгыз/күп балалы әти-әни булып торам<br>Чернобыль һәм башка радиация һәлакәтләре һәм катастрофалар аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданин булам<br>18 яшьтән 25 яшькә кадәр, урта һөнәри белем яисә югары белем алган һәм белем һәм квалификация турында документ бирелгән көннән алып ел дәвамында эш эзләүче гражданин булып торам |

18. Әгәр сез эшсез буларак танылуга дәгъва белдерәсез икән, түбәндәге белешмәләрне раслагыз:

(һәр категория буенча ике вариантның берсен сайлагыз)

Эшсез дип таныла алмый торган һәм туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү өчен генә дәгъва белдерә торган гражданнар категориясе:

- 16 яшькә җитмәгән:

карыйм;

карамыйм;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык (шул исәптән вакытыннан алда) буенча иминият пенсиясе һәм (яки) тупланма пенсия билгеләнгән, яисә эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тәкъдиме буенча пенсия, йә картлык буенча яки тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсия тәэминаты буенча пенсия билгеләнгән:

карыйм;

карамыйм;

- суд карары буенча төзәтү яки мәҗбүри эшләргә, шулай ук шартлы рәвештә җәза билгеләүгә хөкем ителгән затлар, әгәр әлеге җәза шартлы рәвештә

билгеләнмәгән булса:

карыйм;

карамыйм;

- хезмәт шартнамәсе буенча эшләүчеләр, шул исәптән тулы яисә тулы булмаган эш вакыты шартларында түләү өчен эш башкаручылар, шулай ук, сезонлы, вакытлы эшләрне дә кертеп, түләнә торган башка эше (хезмәте) булган затлар, җәмәгать эшләреннән тыш (беренче тапкыр эш эзләүче (элегрәк эшләмәгән) затлар арасыннан (элек эшләмәгән) һәм шул ук вакытта квалификациясе булмаган затлар арасыннан иҗтимагый эшләрдә катнашучы гражданнардан тыш; эшсезлек чоры башланырга бер ел эчендә бер тапкырдан артык мәртәбә хезмәт дисциплинасын бозган өчен яки гаепле башка гамәлләр өчен эштән куылган затлардан; шәхси эшкуарлык эшчәнлеген туктаткан, крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары булудан туктаган затлардан; озакка сузылган өзеклектән соң (бер елдан артык вакыт узгач) хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтыла торган, шулай ук халыкның мәшгульлек хезмәте органнары тарафыннан укытуга юлланган һәм гаепле гамәлләр өчен укудан чыгарылган затлардан; сезонлы эшләрне тәмамлаганнан соң халыкның мәшгульлек хезмәте органнарынна мөрәҗәгать иткән затлардан тыш) һәм  сайлау комиссияләре, даими (штатлы) нигездә хәл иткеч тавыш хокукы белән референдум комиссияләре әгъзалары вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан тыш:

карыйм;

карамыйм;

- шәхси эшкуарлар, шулай ук шәхси тәҗрибә белән шөгыльләнүче нотариуслар, адвокат кабинетларын гамәлгә куйган адвокатлар сыйфатында теркәлгән һәм федераль законнар нигезендә һөнәри эшчәнлеге дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиешле башка затлар:

карыйм;

карамыйм;

- ярдәмче хуҗалыкларда эшләүчеләр һәм шартнамәләр буенча продукция сатучылар:

карыйм;

карамыйм;

- предметы эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган гражданлык хокукы рәвешендәге шартнамәләр буенча эшләр башкаручы, шулай ук җитештерү кооперативларында (артельләрендә) әгъзалар булып торучы затлар:

карыйм;

карамыйм;

- түләнә торган вазыйфага сайлап куелган, билгеләп куелган яки раслап куелган затлар:

карыйм;

карамыйм;

- хәрби хезмәт үтүче, альтернатив гражданлык хезмәтен үтүче, шулай ук эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять-үтәтү системасы оешмаларында һәм органнарында, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында хезмәт итүче гражданнар:

карыйм;

карамыйм;

- халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт оешмасы юлламасы буенча укыту очрагыннан тыш, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге уку рәвешендә белем алучы затлар:

карыйм;

карамыйм;

- эшкә сәләтсезлек, ял, яңадан әзерлек, квалификация күтәрү, эшчәнлекне туктатып тору, баш күтәрү, хәрби җыеннарга чакыру, хәрби хезмәткә (альтернатив гражданлык хезмәтенә) әзерлеккә, башка дәүләт вазыйфаларын үтәүгә һәм башка мөһим сәбәпләр белән бәйле чараларга җәлеп итү нәтиҗәсендә вакытлыча эшләмәүче затлар:

карыйм;

карамыйм;

- оешмаларны гамәлгә куючы (аларда катнашучы) затлар, оештыру-хокук рәвеше әлеге оешмаларның эшчәнлегеннән гамәлгә куючыларның (катнашучыларның) керем алуын күздә тотмаган коммерциясез оешмаларны гамәлгә куючы (катнашучы) затлардан тыш, алар эшчәнлегеннән керем алмый торган гражданнарның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен булдырыла торган торак милекчеләре ширкәтләре әгъзаларын, шулай ук торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары һәм махсуслаштырылган башка кулланучылар кооперативлары әгъзаларын да кертеп:

карыйм;

карамыйм;

- крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзалары булып торучы затлар:

карыйм;

карамыйм;

Минем тарафтан бирелгән мәгълүматлар ялган булса, минем Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла алуым турында миңа кисәтү ясалды.

Әлеге мөрәҗәгать буенча карар кабул итү һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатларында минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белдерәм.

Мин шәхси мәгълүматларны өченче затларга халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатында тапшыруга риза.

Минем гаризамда мәгълүматларның дөрес булмавы расланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенең мине эшсез сыйфатында теркәү исәбенә алудан баш тарта алуы турында миңа кисәтү ясалды.

Ялган юл белән (шул исәптән төгәл булмаган белешмәләр тапшырып та) эшсезлек буенча пособие алган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенең законсыз алынган акчаларны суд тәртиптә түләттерүгә хокуклы булуы, ә тиешле материалларның хокук саклау органнарына тапшырылуы турында миңа кисәтү белдерелде.

Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре белән танышуым турында раслыйм.

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына (белешмәлек) кушымта

# ГРАЖДАННАРГА ТУРЫ КИЛӘ ТОРГАН ЭШ ЭЗЛӘҮДӘ ЯРДӘМ ИТҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕ ТИКШЕРЕП ТОРУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ОРГАННАР (ОЕШМАЛАР) ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт оешмалары

| Халыкның мәшгульлек үзәгенең аталышы | Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|---|
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85592) 7-57-00 | Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84344) 2-74-61 | Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85552) 3-09-83 | Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84341) 2-54-00 | Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84346) 2-15-21 | Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8553) 32-34-99 | Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84376) 2-12-15 | Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84366) 3-29-33 | Centr.Arskiy@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84369) 2-16-50 | Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85569) 5-27-10 | Czn.Bavly@tatar.ru |
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84368) 2-52-34 | Czn.Baltasi@tatar.ru |
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85594) 4-48-53 | Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84374) 3-35-89 | Czn.Buinsk@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84379) 2-18-99 | Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84365) 2-16-17 | CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84375) 2-24-51 | Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85557) 7-58-58 | Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85558) 3-18-92 | Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84371) 5-64-90 | Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84370) 2-10-06 | Czn.Kaybicy@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84364) 2-67-54 | Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84378) 2-48-12 | Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85595) 5-10-40 | Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85563) 3-35-57 | Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерҗе районы филиалы | директор | (85549) 2-02-02 | Czn.Men@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85555) 3-23-80 | Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85556) 2-49-50 | Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | директор | (8552) 52-46-99 | Chelny.CZN@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | директор | (8555) 42-40-79 | Czn.Nk@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84348) 2-30-42 | Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84345) 2-46-32 | Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84367) 3-04-84 | CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84361) 2-21-81 | Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84362) 2-28-15 | SZN.Saby@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85559) 2-42-62 | Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84347) 3-07-72 | Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | директор | (84373) 2-63-29 | Czn.Tetyushi@tatar.ru |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84360) 2-12-68 | Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84396) 2-54-59 | Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84342) 5-30-61 | Czn.chist@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85593) 2-98-00 | Czn.Yutazy@tatar.ru |
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Совет районы филиалы | директор | 562-48-33 | Czn.g Kazan@tatar.ru |
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 537-86-00 | Czn.Avia@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 277-40-42 | Czn.Vah@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 554-77-74 | czn.kirovskiy@tatar.ru |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 564-58-72 | czn.moskovski@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 560-26-95 | Czn.Novosavin@tatar.ru |
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | 224-86-83 | CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Эш белән тәэмин итүдә актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы | 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru». |
| Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек бүлеге | 557-21-58 | Azat.Ayupov@tatar.ru |